ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

17. 04. 2017 г. Казань № 050-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча бирү тәртибен раслау хакында

«Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге № 8-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча бирүнең якынча тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 08.12.2012 № 1068 карарын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче әлеге Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитетының
17.04.2017 №050-од
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты
эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга
аның гарызнамәсе буенча бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге № 8-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча бирүнең якынча тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 08.12.2012 № 1068 карарын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча бирү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

1) Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат – Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында үз вәкаләтләре чикләрендә Дәүләт комитеты тарафыннан булдырылган мәгълүмат (белешмәләр) (шул исәптән документлаштырылган).

Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматка шулай ук Дәүләт комитеты структурасын, вәкаләтләрен, формалашу һәм эшчәнлеге тәртибен билгеләүче закон чыгару һәм бүтән норматив хокукый актлар, аның эшчәнлегенә кагылышлы бүтән мәгълүмат керә;

2) мәгълүматтан файдаланучы – Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат эзләүче граждан (физик зат), оешма (юридик зат), дәүләт органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый берләшмә ;

3) гарызнамә – Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучының телдән яисә язма рәвештә, шул исәптән электрон документ рәвешендә Дәүләт комитетына йә аның вазыйфаи затына кергән мәгълүмат сорап мөрәҗәгать итүе.

## 2. Файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Дәүләт комитетына язма рәвештә алынган гарызнамә кергән көненнән өч көн эчендә теркәлергә тиеш. Телдән тәзелгән гарызнамә, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, кергән көнендә үк теркәлергә тиеш.

2.2. Гарызнамә, Россия Федерациясе законнарында бүтәне каралмаса, ул теркәлгән көннән соң утыз көн эчендә Дәүләт комитеты тарафыннан каралырга тиеш.

Соратылучы мәгълүматны бирү күрсәтелгән срокта мөмкин булмаган очракта, гарызнамәне теркәгәннән соң җиде көн эчендә Дәүләт комитеты мәгълүматтан файдаланучыга гарызнамәгә җавапны кичектерү турында, аның сәбәпләрен һәм соратылучы мәгълүматны бирү срогын күрсәтеп, хәбәр итә, бу срок әлеге Тәртиптә гарызнамәгә җавап бирү өчен билгеләнгән сроктан унбиш көннән дә артмаска тиеш.

2.3. Дәүләт комитеты, мәгълүматтан файдаланучыга Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында кирәкле мәгълүматны бирү максатларында, гарызнамә эчтәлеген төгәлләштерергә хокуклы.

2.4. Мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыга гарызнамәгә җавап рәвешендә бирелә, анда соратылучы мәгълүмат була яисә ул кушып бирелә йә анда әлеге Тәртипнең 2.10 пункты нигезендә әлеге мәгълүматны бирүдән дәлилләнгән баш тарту була.

Гарызнамәгә җавапта Дәүләт комитетының атамасы, почта адресы, җавапка имза салган вазыйфаи затының исеме, шулай ук гарызнамәгә җавапның реквизитлары (теркәү номеры һәм датасы) күрсәтелә.

Гарызнамәгә җавап Дәүләт комитетында билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитетында теркәлә.

2.5. Мәгълүматтан файдаланучы теләге буенча соратып алынучы мәгълүмат аңа телдән яисә документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән кәгазь саклагычтагы документ рәвешендә – почта аша йә электрон документ рәвешендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша җибәрелә.

Мәгълүматтан файдаланучы аны кәгазь саклагычта йә компьютер туплау җайланмасында килеш, йә Дәүләт комитетында үзе турыдан-туры алырга теләгән очракта, Дәүләт комитеты әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган сроклар нигезендә гарызнамәгә җавапта мәгълүматтан файдаланучыга соратылучы мәгълүмат алырга мөмкин булган структур бүлекчә һәм аның вазыйфаи заты турында өстәмә рәвештә мәгълүмат бирә, анда структур бүлекчәнең адресы, телефоны, эш режимы яисә кабул итүнең төгәл датасы күрсәтелә.

Әгәр бу максатларда Дәүләт комитетына махсус кертү режимы билгеләнгән булса, мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматка җавапта бу турыда да хәбәр ителә.

2.6. Мәгълүмат, соратылучы мәгълүмат күләменә һәм форматына карап, түләүсез яисә түләүле нигездә бирелә, шул исәптән күчермәләрне әзерләүгә һәм соратылучы документларны һәм (яисә) материалларны җибәрүгә чыгымнарны исәпкә алып, мондый мәгълүматны бирү тәртибен регламентлаучы законнар нигезендә җибәрелә.

2.7. Мәгълүматтан файдаланучыга түбәндәге мәгълүмат түләүсез нигездә бирелә:

1) телдән тапшырылучы;

2) Дәүләт комитеты тарафыннан Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен бүлеп бирелгән урыннарда урнаштырылучы;

3) кызыксынучы мәгълүматтан файдаланучы хокукларына һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бурычларына кагылышлы;

4) Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында законнар белән билгеләнгән бүтән мәгълүмат.

Мәгълүмат биргән өчен законнар нигезендә түләү алынмый торган очракта, Дәүләт комитеты мәгълүматтан файдаланучыга әлеге Тәртипнең 2.2 - 2.4 пунктларында каралган тәртиптә гарызнамә нигезендә мәгълүмат бирә.

2.8. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргән өчен түләү алу буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24.10.2011 № 860 карары белән расланган кагыйдәләре нигезендә гарызнамә буенча мәгълүмат биргән өчен түләү алу каралган очракта, Дәүләт комитеты:

гарызнамә теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә мәгълүматтан файдаланучыга бу турыда мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча, соратылучы мәгълүмат күләмен һәм форматын, шул исәптән түләү алынырга тиешле мәгълүмат күләмен, өстәмә чыгымнарны кертеп, шушы түләүне исәпләп чыгарып, һәм мәгълүмат алу өчен түләүне күчерүгә түләү документын тутыру өчен кирәкле мәгълүматны күрсәтеп, хәбәр итә;

түләү алу турында раслау алганнан соң мәгълүматтан файдаланучыга әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган тәртиптә әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән срокта мәгълүмат бирә.

Мәгълүмат биргән өчен түләү алынган очракта, мәгълүматтан файдаланучыга ул түләве турында квитанцияне Дәүләт комитетының мәгълүмат бирү өчен җаваплы вазыйфаи затына турыдан-туры күрсәткәннән соң мәгълүмат бирелә.

2.9. Дәүләт комитеты төгәл булмаган белешмәләре белән мәгълүмат биргән очракта, Дәүләт комитеты мәгълүматтан файдаланучының дәлилләнгән язма гаризасы нигезендә булган төгәлсезлекләрне түләүсез бетерергә тиеш.

2.10. Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү сәбәпләрен юкка чыгаручы нигезләр:

1) гарызнамә эчтәлеге Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында соратылучы мәгълүматны билгеләргә ярдәм итми;

2) гарызнамәдә гарызнамә җибәргән мәгълүматтан файдаланучы белән элемтәгә керү өчен гарызнамәгә җавап җибәрерлек почта адресы, электрон почта адресы йә факс номеры күрсәтелмәгән;

3) соратылучы мәгълүмат Дәүләт комитеты эшчәнлегенә карамый;

4) соратылучы мәгълүмат федераль законнар нигезендә файдалануы чикләнгән мәгълүматка керә;

5) соратылучы мәгълүмат элегрәк мәгълүматтан файдаланучыга бирелгән;

6) гарызнамәдә Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителгән актларга хокукый бәя бирү турындагы, эшчәнлегенә анализ уздыру турындагы яисә гарызнамә җибәргән мәгълүматтан файдаланучы хокукларын яклауга бәйле булмаган бүтән анализ эше турындагы сорау куелган.

Әгәр бу мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында басылган яисә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган булса, Дәүләт комитеты үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирмәскә хокуклы. Бу очракта гарызнамәгә җавапта Дәүләт комитеты соратылучы мәгълүмат басылган массакүләм мәгълүмат

чарасының исемен, чыгу датасын һәм номерын һәм (яисә) соратылучы мәгълүмат урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресын күрсәтү белән чикләнә.

2.11. Әгәр гарызнамә үзе җибәрелгән Дәүләт комитеты эшчәнлегенә карамаса, гарызнамә Дәүләт комитетында теркәлгән көннән җиде көн эчендә соратылучы мәгълүмат карый торган дәүләт органына яисә җирле үзидарә органына җибәрелә. Гарызнамәне башка адреска җибәрү турында гарызнамә җибәргән мәгълүматтан файдаланучыга шул ук срокта хәбәр ителә.

Дәүләт комитетының соратылучы мәгълүмат башка дәүләт органында яисә җирле үзидарә органында булу турында белешмәләре булмаган очракта, бу хакта шулай ук гарызнамә теркәлгән көннән җиде көн эчендә гарызнамә җибәргән мәгълүматтан файдаланучыга хәбәр ителә.

Соратылучы мәгълүмат предметы Дәүләт комитеты күрсәтә торган дәүләт хезмәте булган очракта, гарызнамә Дәүләт комитетының шушы хезмәтне күрсәтү өчен җаваплы бүлекчәсенә җибәрелә. Гарызнамәне киләчәктә карау тиешле дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.12. Соратылучы мәгълүмат файдалануы чикләнгән мәгълүматка караган очракта, гарызнамәгә җавапта бу мәгълүматны алу шуның нигезендә чикләнгән акт төре, атамасы, номеры һәм аны кабул итү датасы күрсәтелә. Соратылучы мәгълүматның бер өлеше алуы чикләнгән мәгълүматка караган, калган өлеше алуы мөмкин булган мәгълүматка караган очракта, Дәүләт комитеты соратылучы мәгълүматны алуы чикләнгән өлешеннән башка гына бирә.

2.13. Дәүләт комитетына гарызнамә чит телдә кергән очракта, бу гарызнамә Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә карала.